# Лексикология һәм сөйләм культурасы бүлеген кабатлау.

**Сүз әйтергә тәвәкәллек кирәк,**
**Сүз йөрәккә ялкын үткәрә;**
**Сүз киптерә, төп башына терәп,**
**Сүз меңнәрне яуга күтәрә.**
**Сүз зиһенне кайрый кайрак кебек,**
**Сүз сафларны ипли корычтай;**
**Сүз көрәшкә чыга байрак кебек,**
**Сүз дошманны кисә кылычтай.**

**( Г. Афзал)**

“Сөйләгәндә төкрек чәчмәгез. Бәлки яулык илә авызыгызны каплагыз һәм башыгызны чит тарафка чөегез.”

“Бөекләр сөйләшкәндә, сүзгә катнашмагыз. Бер сүзне күп мәртәбә кабатламагыз.”

“ Кем генә булсагыз да, адәм балалары белән әдәпле мөгамәлә кылыгыз.”

“ Йомшак вә мөлаем сүзле, ихласлы булыгыз.”

Р. Фәхреддин

# Нәрсә ул лексика?

Лексика (грекча – сүз) – сүзләр җыелмасы. Лексика дип теге яки бу телнең сүзлек составын, җирле сөйләшләрдәге сүзләр җыелмасын теге яки бу кешенең сүзләр җыелмасын, әдәби әсәрнең сүзлек составын атыйлар.

# “Лексикология” бүлеге нәрсә өйрәнә?

Лексикология – телнең лексика-
сын өйрәнә торган фән атамасы.

# Лексикография дип нәрсә атала ?

Телдәге сүзләрне җыю, теркәү, сүзлекләр төзү, сүзлекләрнең төрләрен өйрәнүне лексикогра-фия башкара.

# Түбәндәге сүзләр белән туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзтезмәләр төзеп языгыз.

- Кайнар, тәмле, туры, алтын, җылы.

# Дөреслеген тикшер!

- кайнар аш
- тәмле алма
- туры сызык
- алтын йөзек
- җылы көн

- кайнар яшь
- тәмле телле
- туры сүзле
- алтын куллы
- җылы караш

# “ Кем күбрәк ? “

- “ Умырзаая “ сүзеннән кайсы төркем мөмкин кадәр күбрәк сүзләр төзи.

# Түбәндәге мәкальләрдән антонимнарны тап.

- Хезмәтнең тире ачы булса да, җимеше тат-лы.
- Өең кысан булса да күңелең иркен булсын.
- Яхшы тел –яз кебек, яман тел көз кебек.
- Туры әйткән котылган, ялганлаган тотыл-ган.
- Сөйдергән дә - тел, биздергән дә - тел.
- Күп сүзнең азы яхшы.

# Бирелгән сүзләрнең синонимнарын уйлап яз.

- Зифа, өлкән, эссе, дус, саф.

# Дөреслеген тикшер !

Зифа, чибәр, сылу, кәркәм, нәфис,матур.
Өлкән, эре, дәү, олы, зур.
Эссе, кайнар, кызу.
Дус, иптәш, ахирәт, сердәш.
Саф, пакь, керсез, чиста.

# Омоним сүзләр белән җөмләләр төзегез.

- Ат – ат, җәй – җәй, күзге – күзге, йөз – йөз.

# Фразеологизмнарны күрсәтегез.

- 1.телен йоту
- 2. ризыгын йоту
- 3. су йоту
- 4. чәйнәп йоту

- 1. аш пешмәү
- 2. борчак пешмәү
- 3. бәрәңге пешмәү
- 4. ботка пешмәү

# Йомгаклау.

- Дәрестә нинди уку мәсьәләсен чиштек ?
- Дәрескә гомуми бәя кую.
- Өй эше.
- 258 нче күнегү.
- Антонимнар кергән табышмаклар язып кил.